| | | |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.08.2019 пгт. Рыбная Слобода № 260пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 29 гыйнварындагы 36пи номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, 2019 елның 27 июненнән №151-ФЗ номерлы «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы Федераль законга, Россия Федерациясенең аерым закон актларына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. «Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 29 гыйнварындагы 36пи номерлы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 29 маендагы 185пи номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 2 бүлектәге 2.5 пунктны түбәндәге эчтәлекле 6, 7 пунктчалары белән тулыландырырга:

«6) Проект документларына кертелә торган үзгәрешләрнең Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.8 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау, проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы һәм әлеге зат тарафыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, проектның баш инженеры вазифасында архитектура-төзелеш проектлавын оештыру буенча белгеч тарафыннан

расланган, үзеннән-үзе көйләнә торган оешма әгъзасы булган зат тарафыннан бирелгән, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.8 өлеше нигезендәраслау;

7) Проект документларына кертелә торган үзгәрешләрнең Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.9 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.9 өлеше нигезендә экспертлар белән тәэмин итү барышында проект документларына үзгәрешләр кертелгән очракта, башкарма хакимият органы яки Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.9 өлеше нигезендә проект документларына экспертиза үткәргән оешма тарафыннан бирелгән таләпләргә туры килүен раслау;»

1.2) 2.5 пунктның 3 бүлекчәсендәге "проектлы" сүзен "Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясындагы 15 өлеше нигезендә расланган проект" сүзләренә алмаштырырга;

1.3) 2.5 пунктның 4 бүлекчәсендәге "капиталь төзелеш объектының проект документларына экспертиза бәяләмәсе" сүзләрен "капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору эшләре башкарыла торган проект документларына экспертиза бәяләмәсе, шул исәптән әлеге проект документларында, линияле объектларны да кертеп, капиталь төзелешнең башка объектларын төзү яки реконструкцияләү каралган очракта да", сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнашкан рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Д.Н. Ризаевка йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов